ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.11.2025 г. Заинск № 547

**Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 декабрендәге 796 номерлы "2022-2026 елларга Зәй муниципаль районының экологик иминнлек программасын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 декабрендәге 796 номерлы карары белән расланган 2022-2026 елларга Зәй муниципаль районы экологик иминлек Программасы паспортына (Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 13.12.2022ел № 629; 27.10.2023 ел №914; 2025 елның 24 мартындагы №121 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Программаның максатлары һәм бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары һәм бурычлары | **Төп максатлар:**<br><br>- экологик иминлек дәрәҗәсен арттыру һәм табигать системаларын саклау<br><br>- халыкның тотрыклы үсеше һәм социаль- |

| | |
|---|---|
| | икътисадый яклануы өчен кирәкле шарт буларак ресурслардан рациональ һәм экологик яктан хәвефсез файдалану<br><br>- Зәй муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшыртуның кирәкле шарты буларак әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү<br><br>**Төп бурычлар:**<br><br>• Зәй муниципаль районы территориясендә атмосфера һавасының сыйфатын яхшырту.<br><br>• Зәй муниципаль районы территориясендә җир өсте суларының сыйфатын яхшырту.<br><br>• Табигать комплексларын, шул исәптән урманнарны торгызуны, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының биологик төрлелеген саклау һәм торгызу.<br><br>• Халыкның сәламәтлеген яхшырту, авырулар санын киметү.<br><br>• Калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерү системасын кертү.<br><br>• Зәй муниципаль районы территориясендә әйләнә-тирә мохит сыйфатын җайга салу.<br><br>• Территорияне комплекслы бәяләүне тәэмин итү, уңайсыз зоналарны ачыклау, экологик иминлек өлкәсендә мәгълүмат ресурслары булдыру һәм аларга ярдәм итү.<br><br>• Халыкның экологик культура системасын, гражданлык үзаңы дәрәҗәсен һәм әйләнә-тирә мохитнең сыйфатын тәэмин итү өлкәсендәге активлыкны үстерү.<br><br>• Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан экологик законнарның мәҗбүри таләпләрен бозуларны профилактикалау. |

1.2. «Ярдәмче программалар исемлеге» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программалар исемлеге | Программа экологик һәм икътисадый вәзгыятькә бәйле рәвештә даими төзәтелә торган конкрет ярдәмче программалар системасы аша гамәлгә ашырыла:<br><br>1. Техноген йөкләнешләрне киметү буенча табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыру гамәлләре:<br><br>- атмосфера һавасын савыктыру һәм саклау чаралары;<br><br>2. Су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау гамәлләре:<br><br>- халыкны эчәргә яраклы чиста су белән тәэмин итү чаралары;<br><br>- суүткәргечләрне, канализация челтәрләрен һәм корылмаларын киңәйтү, реконструкцияләү һәм төзү гамәлләре;<br><br>- сулыкларны төзекләндерү, ландшафтларны торгызу чаралары.<br><br>3. Җир ресурсларыннан, үсемлекләр дөньясыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау чаралары:<br><br>- җитештерү һәм куллану калдыкларын утильләштерү, туплау, күмү чаралары;<br><br>- җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау чаралары;<br><br>- үсемлекләр дөньясын саклау чаралары;<br><br>- экологик хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау.<br><br>4. Халыкны савыктыруга юнәлдерелгән чаралар;<br><br>5. Халыкны экологик тәрбияләү, белем бирү һәм агарту |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Зәй муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

Э.М. Данилова
8(85558) 9-90-56